ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 501-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 501-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2287-VI ДС

II укылышка әзерләнгән
проект

**«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (Iөлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 35 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:

а) 4 пунктта «шкала билгели» сүзеннән соң «, конкурс документациясен раслый» сүзләрен өстәргә, «йөртүчеләргә» сүзен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның дубликатын һәм тиешле маршрут карталарының дубликатын бирү тәртибен билгели, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның дубликатын һәм тиешле маршрут карталарының дубликатын бирү тәртибен билгели;»;

в) 7 пунктта «регионара һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«8) Федераль законның $3^5$ статьясындагы 4 пункты һәм статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы чикләрендә уза торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның халыкара һәм регионара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларына таләпләрне билгели;»

2) 4 статьяда:

а) 4 пункт «шкала билгели» сүзеннән соң «, конкурс документациясен раслый» сүзләрен өстәргә, «йөртүчеләргә» сүзен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«4[1]) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның дубликатын һәм тиешле маршрут карталарының дубликатын бирү тәртибен билгели, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның дубликатын һәм тиешле маршрут карталарының дубликатын бирү тәртибен билгели;»;

3) 5 статьяда:

а) 2 өлештә «тиешле шәһәр округының» сүзләрен «шәһәр округының» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4[1] өлештә «муниципаль маршрутын» сүзләрен «муниципальара маршрутын» сүзләренә алмаштырырга, «муниципальара маршрутын» сүзләрен «муниципаль маршрутын» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 өлештә «1 – 11» цифрларын «1 – 10» цифрларына алмаштырырга, «3 – 11» цифрларын «3 – 10, 12» цифрларына алмаштырырга, «реестрларыннан шушы маршрутлар турында белешмәләр төшереп калдырылган» сүзләрен «реестрларына шушы маршрутларны туктату турында белешмәләр кертелгән» сүзләренә алмаштырырга;

4) 5[1] статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру форматы, электрон исәпләү машиналары өчен программаларны, текстлы файлларны һәм электрон таблицаларны булдыру, карау һәм редакцияләү өчен каралган белешмәләр базасыннан файдаланып, аларны сайлап алу һәм төрләргә аеру мөмкинлеген күздә тотарга тиеш.»;

5) 7 статьяда:

а) 2 өлештә «ачык конкурс» сүзләреннән соң «(алга таба – ачык конкурс)» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлештә:

1 пунктта «24 статьясындагы 10 өлешендә йә 29 статьясындагы 1 өлешенең 1, 2 яисә 7 пунктларында» сүзләрен «29 статьясындагы 1 өлешенең 1, 2, 7, 9 һәм 11 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3 һәм 4 пунктлар өстәргә:

«3) ачык конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча бирелгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлаганчы юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучының вәкаләтле вәкиле Федераль законның 29 статьясындагы 3 өлеше нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу бурычын үтәмәгән очракта;

4) Федераль законның 29 статьясындагы 7 өлешендә каралган хәлләр барлыкка килгәннән соң.»;

в) 4 өлештә «көндә» сүзен «көннән алып өч көн дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкны биргән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы Федераль законның 29 статьясындагы 5 өлешендә каралган шартларның кимендә берсе генә барлыкка килсә дә әлеге таныклыкның гамәлдә булуын туктату турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә.»;

6) $7^1$ статьяда:

а) «Юридик» сүзен «1. Юридик» сүзенә алмаштырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына, автовокзаллар һәм автостанцияләр хуҗаларына, тукталыш пункты алар территориясендә булган очракта, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутына тарифлар үзгәрү турында үзгәргән тарифны куллануга 15 көн кала хәбәр итүне;»;

в) түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының норматив хокукый акты белән транспорт чарасының экологик характеристикасы буенча билгеләнгән чикләүләрне үтәүне.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган таләпләрнең бозылуы турында белешмәләр вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

7) $7^2$ статьяда:

а) исемдә «йөртүнең һәм багаж ташуның регионара һәм халыкара» сүзләрен «йөртү һәм багаж ташу» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Автовокзал йә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләр нигезендә җиһазландырылган булырга тиеш. Автовокзал йә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары күрсәткечләрендә мәгълүмат урнаштыру вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан оештырыла.»;

8) 11 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 1 пунктының а – в пунктчаларыннан, 2 – 4 пунктларыннан, 5 пунктының б – г пунктчаларыннан, 6 һәм 7 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының а – в пунктчалары, 2 – 4 пунктлары, 5 пунктының б – г пунктчалары, 6 һәм 7 пунктлары 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына үзгәрешләр таблицасы**

| № Т/б | Гамәлдәге редакция | 1 нче укылышта кабул ителгән редакция | Үзгәрешләр | Үзгәрешләр исәпкә алынган редакция |
| --- | --- | --- | --- | --- |
| 1 | 3 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре**<br>…<br>2. Вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы:<br>…<br>8) Татарстан Республикасы чикләрендә уза торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларына таләпләрне билгели;<br>… | **1 статья**<br>1) 3 статьяның 2 өлешендә:<br>…<br>г) 8 пунктта «регионара маршруты» сүзләрен «регионара һәм халыкара маршрутлары» сүзләренә алмаштырырга; | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты**<br>1 статьяның 1 пунктындагы «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br>г) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә<br>«8) Федераль законның $3^5$ статьясындагы 4 пункты һәм статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы чикләрендә уза торган даими рәвештә | <u>**1 статья**</u><br>1) <u>3 статьяның 2 өлешендә:</u><br><u>г) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u><br><u>8) Федераль законның $3^5$ статьясындагы 4 пункты һәм статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы чикләрендә уза торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның халыкара һәм регионара маршрутлары буенча</u> |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның халыкара һәм регионара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларына таләпләрне билгели;» | даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларына таләпләрне билгели;» … |
| 2. | $7^1$ статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга таләпләр**<br>Юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе законнарында, әлеге Законда | **1 статья**<br>б) $7^1$ статьяда:<br>а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br>«3) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына, автовокзаллар һәм автостанцияләр хуҗаларына, тукталыш пункты алар территориясендә булган очракта, даими | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты**<br>1 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br>«б) $7^1$ статьяда:<br>а) «Юридик» сүзен «1. Юридик» сүзенә алмаштырырга;<br>б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br>«3) вәкаләтле | **1 статья**<br>б) $7^1$ статьяда:<br>а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br>«3) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына, автовокзаллар һәм автостанцияләр хуҗаларына, тукталыш пункты алар территориясендә булган очракта, даими |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | билгеләнгән таләпләрне үтәргә, шул исәптән түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:<br>…<br>1) билгеләнгән тәртиптә ГЛОНАСС яисә ГЛОНАСС/GPS спутник навигациясе аппаратурасы белән җиһазландырылган транспорт чараларыннан файдалануны һәм мондый транспорт чараларыннан “ГЛОНАСС+112” бердәм дәүләт мәгълүмат системасына өзлексез рәвештә (даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының билгеләнгән расписаниесе чикләрендә) мәгълүмат тапшыруны;<br>2) инвалид булган пассажирларны йөртү өчен транспорт чарасында куелган җиһазның, һава температурасын тикшереп тору системасының, электрон мәгълүмат таблосының, транспортта йөргән өчен акчаны күчереп түләү җайланмасының төзек эшләвен; | рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутына тарифлар үзгәрү турында үзгәргән тарифны куллануга 15 көн кала хәбәр итүне;»;<br>б) түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:<br>«5) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының норматив хокукый акты белән транспорт чарасының экологик характеристикасы буенча билгеләнгән чикләүләрне үтәүне.»; | Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына, автовокзаллар һәм автостанцияләр хуҗаларына, тукталыш пункты алар территориясендә булган очракта, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутына тарифлар үзгәрү турында үзгәргән тарифны куллануга 15 көн кала хәбәр итүне;»;<br>в) түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:<br>«5) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының норматив хокукый акты белән транспорт чарасының экологик характеристикасы буенча билгеләнгән чикләүләрне үтәүне.»;<br>г) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә: | рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутына тарифлар үзгәрү турында үзгәргән тарифны куллануга 15 көн кала хәбәр итүне;»;<br>б) түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:<br>«5) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының норматив хокукый акты белән транспорт чарасының экологик характеристикасы буенча билгеләнгән чикләүләрне үтәүне.»; |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | «2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган таләпләрнең бозылуы турында белешмәләр вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»; | |
| 3. | $7^2$ статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара һәм халыкара маршруты буенча автовокзаллар яисә автостанцияләр территорияләреннән читтә урнашкан тукталыш пунктларыннан файдалану**<br><br>....<br>2. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара яисә халыкара маршруты буенча автовокзал йә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары, әлеге | **1 статья**<br>7) $7^2$ статьяда:<br>б) 2 өлештә «Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның регионара яисә халыкара маршруты буенча» сүзләрен төшереп калдырырга, «регионара яисә халыкара маршрут буенча» сүзләрен төшереп калдырырга; | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты**<br>1 статьяның 7 пунктындагы «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br>б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br>«2. Автовокзал йә автостанция территориясеннән читтә | **1 статья**<br>7) $7^2$ статьяда:<br>....<br>б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br>«2. Автовокзал йә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөрту |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | статьяның 1 өлешендә каралган очракта, Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләр нигезендә җиһазландырылган булырга тиеш. Автовокзал йә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары күрсәткечләрендә регионара яисә халыкара маршрут буенча мәгълүмат урнаштыру вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан оештырыла. | | урнашкан тукталыш пунктлары Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләр нигезендә җиһазландырылган булырга тиеш. Автовокзал йә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары күрсәткечләрендә мәгълүмат урнаштыру вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан оештырыла.»; | һәм багаж ташу кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләр нигезендә җиһазландырылган булырга тиеш. Автовокзал йә автостанция территориясеннән читтә урнашкан тукталыш пунктлары күрсәткечләрендә мәгълүмат урнаштыру вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан оештырыла.»; |